# 13 сентябрьдә – барыбыз да сайлауларга!


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга
11
сентябрь
2015 ел

№ 67 (10596)


**12 сентябрьгә һава торышы:** аз болытлы һава, җил төньяктан, 3-5 м/с; температура көндез +15°C, төнлә +9°C

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### Нурлатлыларны бәйрәм көтә

Бүген 17.30 сәг.тә шикәрчеләр бистәсендә "Дуслык" скверын тантаналы ачу була. 18.00 сәгатьтә Халыклар дуслыгы йортында нурлатлыларны күпмилләтле Татарстан Халыклар дуслыгы Ассамблеясы һәм Йорты әзерләгән "Дуслар җыелган җирдә"– "Мы вместе–и в этом наша сила" дип аталган зур концерт көтә. **Бәйрәмгә рәхим итегез!**

### РАЙОНДА – ЯҢА ПРЕДПРИЯТИЕ

Бүген "ТНП-Зүзәйнефть" территориясендә "Сервис хезмәтләре үзәге" җәмгыяте ачыла. Ул нигездә тирәндәге насос җайланмаларын ремонтлау һәм диагностикалау белән шөгыльләнә. Ачылу тантанасы хакында җентеклерәк "Дуслык"ның чираттагы номерыннан укыгыз.


ПРИГЛАШАЕМ НА РАБОТУ
**ВАХТОВЫМ МЕТОДОМ**
*в Москве мужчин и женщин!*
**Мы предоставляем:**
*Высокую оплату труда*
*Бесплатное проживание*
*Еженедельные авансы*
*Корпоративный транспорт.*
**Звоните:**
**8 495 646 71 66,**
**8 966 135 61 88**
Реклама



# Рөстәм Миннеханов: *"Без бердәм һәм көчле булырга тиеш"*



Тулырак "Атна вакыйгалары"ннан укыгыз

БЕЗНЕҢ СОРАШТЫРУ

## Мин ни өчен сайлауларга барачакмын?



**Ислам Сафиуллин, районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы:**

*. Нәкъ менә сайлаулар көне якындагы елларга безнең тормышыбызны билгеләячәк. Сайлауга бару, уйлап тавыш бирү, ягъни үз гражданлык позицияңне белдерү мөһим. Мин сайлауларга һәрчак йөрим һәм бу хакта якыннарымның да исенә төшереп торам. Без киләчәгебез, авылларыбызның үсеш перспективасы өчен тавыш бирәбез. Шуңа да мин бар авыл халкын һәм нурлатлыларны да якшәмбе көнне үз сайлау участокларына килеп, тавыш бирүдә катнашырга чакырам.*



**Илүзә Билалова, Нурлат:**

*– Без гадәттә тавыш бирергә бөтен гаиләбез белән барабыз. Улыбыз Искәндәргә бу процесс аеруча ошый. Миңа калса, баланың активлыкны, иҗтимагый тормышта катнашу кирәклеген күреп үсүе мөһим. Безнең сайлау участогында сайлаулар һәрчак бәйрәмчә, матур уза. Бу шулай булырга тиеш тә, чөнки ул бик җаваплы көн бит. Танышларым да шулай дип саный, сайлауларга берәү дә битараф булырга тиеш түгел. Без эшләмәсәк, моны безнең өчен кем башкарыр?*



**Максим Сычев, студент, Нурлат – Самара:**

*– Быел мин Самара дәүләт юллар университетының электр белән тәэмин итү факультетына укырга кердем. Быел республикада сайлаулар көтелә. Минем танышларым һәм якыннарым да сайлауларны хуплыйлар. Яшьләр дә, өлкән буын да тавыш бирүгә җаваплы карыйлар. Мин дә мондый мөһим вакыйгадан читтә калырга ярамый, дип уйлыйм. Шулай итеп, нурлатлылар, сайлау участокларына барыйк һәм тавыш бирик!*



**Ирина Ефимова, Нурлат – Казан:**

*– Үземне актив тормыш позицияле кеше дип атый алам. КНИТУда укыганда, мин Универсиада-2013тә волонтерлар белән эшләү департаментында тим-лидер булдым . Хәзер банкта өлкән икътисадчы булып эшлим. Сайлауларга җитди карыйм, үзеңнең һәм Татарстанның киләчәге синең нинди сайлау ясавыңа да бәйле бит. Мин алдан ук тавыш бирдем инде. Миңа калса, тавыш бирү көннәре Нурлатта бәйрәм кебек уза. Студентлар һәм башка шәһәрләрдә яшәүчеләр дә күпләп шәһәргә кайта.*



**Искәндәр Әхмәдиев, Нурлат УТТсы:**

*– Безнең коллективта күптән килә торган традиция яши – без сайлауга иртүк барабыз. Хәзер, вакытыннан алда тавыш бирү мөмкинлеге булгач, күпләр алдан сайлап куя. Бу шоферлар, эшләре үзгә режим белән баручылар өчен җайлы. Мондый чаралар барышында барыбызга да берләшергә, сайлау участогына килеп, үз төбәгебезнең язмышын хәл итүдә катнашырга кирәк. Шәһәрнең иҗтимагый тормышында һәрчак актив катнашучы нефтьчеләр бу юлы да сынатмаслар һәм тату булып сайлауларда катнашырлар дип уйлыйм.*



**Эльвира Баймурзина, "Шифа" фреш-маркеты кибете мөдире:**

*- Күпчелек нурлатлылар кебек үк, без дә сайлауга гаиләбез белән барабыз. 2нче мәктәп бу көнне аеруча тантаналы була. Мин Татарстаныбызның алга таба ничек үсүе, балаларыбызның киләчәк тормышы өчен борчылам. Бу безнең дә киләчәгебез бит, һәм без аның өчен җаваплы. Һәм сайлаулар – үз фикереңне белдерү, ышанычлы кандидат өчен тавыш бирү мөмкинлеге. Без тавыш бирергә һичшиксез барачакбыз.*

Валентина **ВАФИНА** сөйләште.

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

САЙЛАУ АЛДЫ АГИТАЦИЯСЕ

# Рөстәм Миннеханов – безнең Президент

## Нурлат шәһәре һәм районы халкы үз сайлауларын ясадылар



**Ильяс ӘНДАРОВ, "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы урынбасары:**

– Республика зур адымнар белән алга атлый. "Татарстан – *мөмкинлекләр территориясе" дигән сүзләр телдән-телгә йөри. Иннополис, IT-парк уникаль инновацион проектлары тормышка ашырыла. Илнең "ТАНЕКО", "ТАИФ-НК" кебек эре сәнәгать комплекслары, "Алабуга" икътисади зонасы уңышлы эшли. "Татнефть" компаниясе дә илнең икътисадына саллы өлеш кертә. Боларның барысы да – яңа формациядәге, заманча фикер йөртүче, көчле җитәкче Рөстәм Нургалиевичның кушуы буенча эшләнгән Стратегия 2030 нәтиҗәсе. Әлбәттә, үсеш һәм перспективага йөз тоткан курс дәвам да иттерелергә тиеш. Без үз Президентыбызга ышанабыз! Ул – безнең кандидат! Ул – безнең лидер! Мин Нурлат нефтьчеләренең 13 сентябрь көнне үз тавышларын Миннеханов өчен бирәселәренә ышанам. Бары аның белән генә Татарстаныбыз чәчәк атачак.*



**Разия САДРЕТДИНОВА, районның ветераннар Советы рәисе:**

*– Мин Президент праймеризларында сайлаучы буларак катнаштым. Праймеризларның күләмле мохитында без татарстанлыларны Рөстәм Нургалиевич Миннехановка бердәм ышаныч белдерүенә инандык. Ул – дәрәҗәле сәясәтче, зирәк һәм алга карап эш йөртә белүче җитәкче. Без барын да булдырачакбыз – моны ул үзенең сүзләре һәм эше белән исбатлады. Татарстанда гомер озынлыгы 72 елдан артып китте. Пенсионерлар һәм ветераннарга кагылышлы барлык социаль бурычлар да үтәлеп килә. Бөек Җиңүнең 70 еллыгында бер генә фронтовик, бер генә тыл хезмәтчәне дә игътибарсыз калмады. Без барыбыз да бездә кешенең иң кадерле зат булуына инандык. 13 сентябрь – бердәм тавыш бирү көнендә без, район һәм шәһәр пенсионерлары, барлык нурлатлыларны да безнең кандидат – Рөстәм Нургалиевич Миннеханов өчен тавыш бирергә чакырабыз.*



**Эмиль ГАЛЛӘМОВ, 2нче мәктәпнең физкультура укытучысы, спорт мәктәбе тренеры:**

*– Безнең республикада 30 республика президенты социаль программасы гамәлдә. Аларның күбесе халыкның яшәү шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән. 2013нче елда районның барлык мәктәпләре дә спорт җайланмалары белән җиһазландырылды. Соңгы ике елда шәһәрдә республика президент программасы буенча 6 универсаль спорт мәйданчыгы булдырылды, стадион төзелеп килә. Үз эшеңне башларга, сәләтеңне күрсәтергә мөмкинлекләр бар. Спорт казанышларын үстерүгә Бөтендөнья Универсиадасы һәм Дөнья чемпионаты үткәрү дә йогынты ясады һәм Рөстәм Нургалиевич Татарстанның үсешенә бәяләп бетергесез өлеш кертте. Без барыбыз да республикабыз лидерының ярдәмен тоябыз, аңа киләчәгебезне ышанып тапшырабыз һәм аның өчен тавыш та бирәчәкбез. Татарстанны тагы да үстерү өчен аның көче дә, мөмкинлекләре дә җитәрлек. Нәкъ менә шуңа да 13 сентябрь көнне тавышыбызны үз Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миннеханов өчен бирәчәкбез.*



**Ильяс ТЯМАЕВ, фермер:**

– Без үз хезмәтебезгә таянып *яшибез. Шөкер, моның өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Республика авыл хуҗалыгы җитештерүе буенча Россиядә өченче урында тора, илдә иң эре сөт җитештерүче төбәкләрдән санала. Боларның барысы да – безнең Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миннехановның тырышлыгы нәтиҗәсе. Ул һәрбер кешенең тормышы яхшы булсын дип кайгырта. Моңа мисаллар җитәрлек. Мәсәлән, күптән түгел безнең гаилә фермасына кадәр юл салдылар, техника белән ярдәм иттеләр. Мин сайлау ясадым инде. Мин үз тавышымны Рөстәм Нургалиевич өчен бирәчәкмен. Мин бары аны гына Татарстан Президенты ролендә күрәм. 2015нче елның 13 сентябрендә сайлау участогына килгәндә һәркем үз киләчәге турында уйланырга һәм дөрес сайлау ясарга тиеш. Нурлатлылар – республикабызның чәчәк атуы өчен! Без – Миннеханов яклы!*



**Гөлфия ГАФУРОВА, мәгълүмати-методик үзәк җитәкчесе:**

*– Безнең республикада мәгариф – инновацион технологияләргә бай өлкә. Республикада 36 меңнән артыграк яңа мәктәпкәчә урын булдырылды, 200дән артыграк балалар бакчасы, 37 мәктәп төзелде. 63тән артыграк мәктәп һәм балалар бакчасы ремонтланды. Күләмле үзгәрешләр безнең район кешеләрен дә сөендереп тора. Балалар өчен барлык шартлар да тудырылган, демографик күрсәткечләр үсә, димәк, республикабызның киләчәге бар. Боларның барысы да безнең лидерыбыз Рөстәм Нургалиевич Миннеханов тоткан курс нәтиҗәсендә мөмкин булды. Аның эш нәтиҗәләре – безнең күз алдында, бу тормышыбызның яхшыруы. Зирәк сәясәтче, нәтиҗәле лидер – Президент вазифасында мин бары тик аны гына күрәм. Аның кул астында Татарстанның билгеләнгән планнарын тормышка ашырасына, республикабызда тынычлык һәм килешү хакимлек итәсенә ышанырга мөмкин. Үз сайлавыгызны нәтиҗәле лидер өчен ясагыз, Миннеханов өчен тавыш бирегез!*



**Гүзәлия КУЛЬМЕТЬЕВА, пенсия фонды идарәсенең кадрлар буенча белгече:**

*– Мин республикабыз лидеры Рөстәм Нургалиевич Миннеханов өчен тавыш бирәчәкмен. Ул республика белән җитәкчелек иткән биш ел эчендә ниләргә ирешеп булуын күрсәтте. Аның инициативасы белән мөһим документ – Стратегия 2030 кабул ителде. Игътибар үзәгенә кеше һәм аның иминлеге куела. Мин республикабыз, төбәгебезнең тотрыклы үсеше яклы. Хәзер Нурлатта яшьләр өчен мөмкинлекләр күп: белем алудан эшмәкәрлеккә кадәр. Бу сайлаулар – мөһим сәяси вакыйга. Соңгы тапкыр Президент сайлаулары 2001 елда үткән иде. Киләчәгебез хәл ителгән әлеге вакыйгадан без читтә кала алмыйбыз. Сайлауларга һичшиксез барырга һәм үз гражданлык позициябезне күрсәтергә кирәк. Мин – Миннеханов яклы, мин – уңышлы Татарстан өчен!*

**Агитация материалы Татарстан Республикасы Президентлыгына кандидат Рөстәм Нургали улы Миннеханов тарафыннан бирелде, ТР Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә түләүсез бастырыла.**

# Кече авыллар үсеше – өстенлекле юнәлеш

ИНФРАСТРУКТУРА

**Районның Иске Авыл, Кара Күл, Кече Камышлы авыллары бүген кече авыллар статусында булсалар да, яңа өметләр, планнар белән яшиләр.**

- Мин үзем Кара Күл авылында туып үсеп, мәктәпне тәмамладым, - ди бүген Ульян шәһәрендә яшәүче Гөлзәминә Сатдарова. – Ел саен җәйге ялларны туган авылымда үткәрәм. Алга таба лаеклы ялга чыккач та туган авылыма кайтып төпләнү хыялы белән яшим. Акрынлап кына туган нигезне ремонтлап киләбез. Теләгән кешегә кече авылда да яшәргә мөмкинлекләр җитәрлек бит. Иң мөһиме - яшәү өчен газ, су, юллар гына булсын.

Сишәмбе көнне район башлыгы Равил Кузюров әлеге авылларда булып, халык белән очрашты. Очрашу авыл кешеләренең тормыш шартларын комплексны яхшыртуга корылган иде. Авыллар кече булсалар да, халык бирегә кайтып төпләнә. Җир участоклары сатып алалар, йортлар төзиләр. Иске Авылда бүгенге көндә 22 йорт исәпләнә.

- Республикада тормышка ашырылучы федераль һәм җирле президент программалары авылга ярдәм итүгә юнәлдерелгән,– диде район башлыгы халык белән очрашу вакытында. – Авыл – безнең дәүләтебезнең нигезе. Һәм без анда яшәүчеләргә ярдәм итәчәкбез.

Район башлыгының Иске Авылга газ кертү буенча план – проект эшләнә башлау турындагы яңалыгын һәм Кара Күлгә керә торган юлны торак пунктларның урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерү республика программасына кертәчәкләр дигән хәбәрләрен дә әлеге авыллар халкы: "Хәерле сәгатьтә", - дип каршы алдылар.

- Ел саен республика президент программалары ярдәмендә авылларны төзекләндерү буенча эшләр алып барабыз, - диде район башлыгы. – Зур авыллар белән беррәттән кече авылларны да онытмыйбыз.

Әлеге авылларда соңгы елларда электр баганалары алмаштырылган, яктырткычлар куелган. Авыл халкы моның өчен дә район җитәкчелегенә рәхмәтле.

Кече Камышлы авылы халкы да район җитәкчелегенә рәхмәт хисләре белән яши бу көннәрдә. Быел авыл халкы өчен мәктәпкә кадәр юл төзү зур шатлык булган. Эш визиты барышында район башлыгы Кече Камышлы авылында булып юл, плотина һәм күпер төзелешен дә карады. 1 августтан башланган юл эшләрен "ПКиМ" төзелеш компаниясе башкара.

- 1560 метрда җир эшләре башкардык, - ди подрядчы оешма мастеры Азат Кучурбаев. – Юлның нигезен – җир эшләрен, вак таш түшәүне ай азагына кадәр эшләп бетерергә планлаштырабыз.

Авыллар картая дисәләр дә, әлеге кече авылларга кайтып төпләнергә теләүче яшьләр дә бар икән. Иң мөһиме – эш урыны гына булсын. Ә биредә шәхси ярдәмче хуҗалыклар ярдәм булачак. Шәхси ярдәмче хуҗалыклар – терлек үстерүчеләрне һәм аларның гаиләләрен,



Автор фотосы

КЕЧЕ АВЫЛЛАРГА РЕСПУБЛИКА ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ ЯРДӘМГӘ КИЛӘ

туганнарын, танышларын азык – төлек белән тәэмин итү чыганагы. Шул ук вакытта артып калган продукция сатуга, эшкәртүгә җибәрелә. Нәкъ менә шәхси хуҗалыклар авылларны саклауда, эшсезлекне киметүдә, тормыш сыйфатын күтәрүдә зур ярдәм булачак. Район башлыгының кече авыллар халкы белән очрашуы да шундый фикер белән тәмамланды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

МӘГАРИФ

# Балалар робот җыя

**Балаларның һөнәри ориентациясе формалашуда иң мөһим алым – фәнни-техник иҗат.**

Ул техника һәм фәнгә кызыксыну уята, шулай ук рационализаторлык һәм иҗади сәләтләрне стимуллаштыра. Бүген районда фәнни – техник иҗатка багышланган 56 түгәрәк эшли. Бу – 2013-14 уку елына караганда 32гә артык. Фәнни – техник иҗат белән район укучылары хезмәт дәресләрендә һәм сыйныфтан тыш чараларда да шөгыльләнә.

- Илебезнең талантлы инженерлары һәм галимнәре – яңа инновацион технологияләрне иҗат итүчеләр, фән һәм техника дөньясына тәүге адымны нәкъ менә шул түгәрәкләрдән башлыйлар, - ди Балалар иҗаты үзәге директоры Галина Мельникова. – Иң мөһиме, балалар компьютер, я булмаса телефонда уйнап утырмый. Балалар эш белән мәшгуль булсыннар.

Күп балалар көнкүреш техникаларын сүтеп җыярга ярата. Еш кына аларның яңа иҗат җимешләре көнкүрештә яраклы әйбергә әйләнә.

- Балаларның техник иҗатка кызыксынулары арту дәресләр санының күбәюе белән бәйле, - ди район мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары Эльмира Шагаева. – Бүгенге көндә түгәрәкләрдә барлыгы 746 укучы шөгыльләнә. Шунысын әйтергә кирәк, районда фәнни – техник юнәлеш барлык сыйныф балаларын да берләштерә. Мисал өчен, техник модельләштерү белән укучылар башлангыч сыйныфта ук шөгыльләнәләр. Кәгазь, картоннан кул эшләре ясыйлар. "Легоконструирование" түгәрәгендә йөрүче кызлар һәм малайлар "Лего" җыелмаларыннан төрле конструкцияләр җыялар. "Столярлык" түгәрәгенә йөрүчеләр агач белән эшлиләр. Узган уку елында районның 6 мәктәбе һәм Балалар иҗаты үзәге "Татнефть" линиясе буенча "NNOVA 3D-принтерлары" алдылар. Шул уңайдан район мәктәпләрендә "3D-киңлек" дип аталган яңа түгәрәк эшли башлады. Анда укучыларны модельләрне программалаштырырга өйрәтәләр. "Робототехника" түгәрәге 3нче елын гына эшләсә дә, нурлатлылар – гимназия укучылары Россия күләмендә чыгыш ясады инде. Моннан тыш, укучыларыбыз техника: самолетлар, автомобильләр җыю белән дә мәшгуль. Бу эшләр "Техник модельләштерү", "Судомоделирование", "Авиомоделирование", "Автомоделирование" түгәрәкләрендә башкарыла. "Уйлап чыгаручылар академиясе", "Радиотехника" түгәрәкләрендә балалар гамәлдәге приборларны төзү белән шөгыльләнәләр. Балалар үз эшләре белән төрле дәрәҗәдәге фәнни – гамәли конференцияләрдә, техник иҗат конкурсларында катнашып, призлы урыннар яулап килләр.

Зилия ӘКСАНОВА



УКУЧЫЛАР КАРТЛАР ҺӘМ ИНВАЛИДЛАР ЙОРТЫНДА ЧЫГЫШ ЯСАДЫ

Автор фотосы

# Игелек җирдә ятмый

**"Күзгә игелек атнасы – игелекле гамәлләр эстафетасы" республика акциясенә нурлатлылар да кушылды.**

7–14 сентябрьдә узучы иркәле акциядә районның барлык мәгариф учреждениеләре, мәдәният йортлары, клублар, китапханәләр һәм волонтерлар катнаша.

– Акциянең беренче көнендә үк мәгариф учреждениеләрендә "Бергәләп ясыйк" Бөтенроссия экология дәресе узды, - диде шәһәрнең 2 нче урта мәктәбе педагог-оештыручысы Айгөл Сәлахова. – Укучыларыбыз "Игелекле сүз" чарасында шигырьләр конкурсында да катнашты.

Ә чәршәмбе көнне шәһәрнең 5 мәктәбе укучылары һәм район мәдәният бүлегенең иҗат коллективы Нурлат картлар һәм инвалидлар йортында яшәүчеләр янына зур концерт программалары белән барды. Өлкәннәрнең хәлләрен белеп, аларга концерт номерлары тәкъдим иттеләр. Әлеге акция өлкәннәргә игътибар күрсәтү һәм игелекле сүзләр җиткерү форсаты да булды.

Атна дәвамында районда шактый игелекле гамәлләр планлаштырган. Бу – спорт чаралары, ветераннарга, инвалидларга һәм тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм күрсәтү. Агачлар утырту, сквер-паркларны җыештыру, һәйкәлләрне ремонтлау.

Игелек чаралары районда елына ике тапкыр – язын һәм көзен уза. Акция барышында районның битараф булмаган һәр актив кешесе дә ярдәмгә мохтаҗ катламга булышлык итә ала.

Зилия ӘКСАНОВА

## УҢЫШЛАРЫ МУЛ БУЛГАН

**Киекле мәктәбенең укыту-тәҗрибә участогы республика смотр-конкурсында катнаша.**


Мәктәп коллективы быел да үз бакчаларында мул яшелчә уңышы үстергән. Суганны гына да 2967 кг җыйганнар, бу узган елгыдан 200 кг.га артыграк. Кәбестәләре 414, кыярлары – 397, кишерләре 2897шәр килограмм булган. 100ләп банка кыяр тозлаганнар, 87 килограмм алма кайнатмасы әзерләгәннәр. Боларның барысы да уку елы дәвамында укучылар өстәлендә булачак. Ә алар мәктәп ашханәсендә укыту-тәҗрибә участогында үстерелгән яшелчә, җиләк-җимешләре хисабына бушлай тукланалар. Мул уңыш исә үзләреннән артканны сатарга да мөмкинлек бирә. Кергән акчаларга эш кирәк-яраклары, ассортиментны төрләндерү өчен яңа сортлы орлыклар сатып алалар.

1 гектар мәйданлы участокта теплица да урнашкан, анысының да файдасын күрәләр. Бирегә яздан үсентеләрне күчерәләр, алар соңыннан ачык һавага чыгарыла. Боларның барысы да технология укытучысы Гөлчәчәк Гыйматова җитәкчелегендә укучылар һәм укытучылар көче белән башкарыла. Чәчәклекләре дә мәктәпнең бизәге булып тора, аның дизайны һәм планировкасы белән биология укытучысы Залия Галәветдинова шөгыльләнә. Кыскасы, укыту-тәҗрибә участогы республика бәйгесендә коллегалары өчен лаеклы көндәш булачак.

Маргарита ЛИТТА

ЙӨРӘК-КАН ТАМЫРЛАРЫ АВЫРУЛАРЫНА КАРШЫ КӨРӘШ ЕЛЫ

# Кибеттә кан басымын үлчәттеләр




Автор фотосы

**Нурлат район хастаханәсенең медицина хезмәткәрләре нурлатлылар өчен күчмә караулар оештыруларын дәвам итәләр. Йөрәк-кан тамырларына авыруларына каршы көрәш елы кысаларында алар узган атнада "Шифа" сәүдә үзәгендә барлык теләүчеләрнең дә артериаль һәм күз басымнарын үлчәделәр.**

Мондый чараларның нәтиҗәлелеге күз алдында: мөрәҗәгать иткән 60лап кешенең 18ендә кан басымының югары булуы ачыкланды. Медицина хезмәткәрләре аларга дарулар бирделәр һәм табибка барырга киңәш иттеләр. Күз басымын тикшертергә 42 кеше теләк белдерде.

- Хәзер артериаль кан басымы проблемасы актуальгә әверелде, - ди гомумпрактика шәфкать туташы Людмила Камышина. – Безнең акциядә катнашырга теләк белдерүчеләр һәрчак күп була, чөнки һәркемнең дә кан басымын үзлектән үлчәү мөмкинлеге юк бит.

– Кан басымын көн саен үлчәп торсалар, һәрчак кереп торыр идем әле, - ди Надежда Вәлиева. – Үземнең тонометрым юк, ә кан басымы соңгы араларда я күтәрелә, я төшә. Өстәвенә, бирәдә медицина хезмәткәрләре кайсы даруны эчәргә кирәклеген дә әйтәләр. Моңа кадәр бер тапкыр да күз басымымны үлчәткәнем юк иде, җае чыкты менә.

Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш елында Нурлатның медицина хезмәткәрләре мондый акцияләрне район администрациясендә, НУБРда, "Нурлатнефть" НГДУсында, "Нурлатгаз" ЭПУсында һәм башка предприятиеләрдә үткәрделәр. Чараларны алар алга таба да дәвам итәчәкләр.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

## ИГЪТИБАР: ЯҢА КОНКУРСЛАР!

### "СӨЙКЕМЛЕ ЕЛМАЮ"

2 октябрь – Бөтендөнья елмаю көне уңаеннан редакция "Сөйкемле елмаю" дип аталган яңа конкурс игълан итә. Хөрмәтле газета укучыларыбыз, "Дуслык" район газетасы сезгә елмаюыгыз белән уртаклашырга тәкъдим итә. Сездән – елмаюлы фотолар, ә бездән – приз. Ашыгыгыз, нәтиҗәләрне 2 октябрьдә ясаячакбыз. Фотоларны редакция адресына яки электронкага (redak@list.ru)җибәрегез.

### "ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: МИНЕМ ЯРАТКАН ЙОРТ ХАЙВАНЫМ"

Шундый исем астында район газетасы редакциясенең махсус проекты старт ала. Ул 4 октябрьдә билгеләп үтеләчәк Бөтендөнья хайваннар көненә багышлана.


"Дуслык" укучылары һәм безнең белән яраткан йорт һәм ишегалды хайваннары тормышыннан кызыклы фотоларыгыз белән уртаклашыгыз. Фотоларны электрон адреска җибәрегез яки 4 октябрьгә кадәр редакциягә китерегез. Аларның барысы да сайтыбызда урнаштырылачак, ә иң кызыклылары газета полосаларын бизәячәк. Җиңүчеләрне мавыктыргыч приз көтә!

## КАБУЛ ИТҮ БУЛА

**15 сентябрьдә** шәһәр Мәдәният сараенда **11.00–13.00** сәгатьләрдә Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары **Мөхәррәм Мансур улы Ибятов** гражданнарны кабул итү үткәрә. Белешмәләр өчен тел.: **2-06-05**

## ЭКСТРЕМИЗМГА – ЮК!

# Иминлек өчен сак булу кирәк



ТИМЕР ЮЛ ВОКЗАЛЫНДАГЫ ЗАМАНЧА ЭЛЕКТРОН ҖАЙЛАНМА ЯШЕРЕЛГӘН МЕТАЛЛ ӘЙБЕРЛӘРНЕ "КҮРЕРГӘ" СӘЛӘТЛЕ

**1 сентябрьдән 30ына кадәр районда "Экстремизмга – Юк!" дип аталган айлык үтә. Бу хакта карарга район башлыгы Равил Кузюров кул куйды.**

Бу чорда шәһәр һәм авылларда милләтара һәм конфессияара килешүгә, терроризм һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлтелгән чаралар үтә. Сентябрьнең беренче көннәренә планлаштырылганнары үтте дә инде: мәктәпләрдә "Экстремизмга – Юк!" дип аталган бердәм республика дәресләре оештырылды, районның мөселман һәм православия дине әһелләре мәчет һәм чиркәүләрдә террористик актлар корбаннары рухына багышлап догалар укыдылар... Каршы тору, алдан күрү, булдырмау – экстремистик күренешләргә каршы торуның мөһим таләпләре шулар. Алар нидән башлана соң?

**Барыннан да элек, балалар һәм үсмерләрне радикаль мәгълүматтан саклаудан.** Интернетның киң таралыш алуыннан экстремистик оешмалар бик оста файдалана. Экстремистик төркемнәр җәмгыятьне мәгълүматлаштыруның бу процессын очраклы гына сайламый – керү ансат, мәгълүмат тиз тарала. Район мәктәпләрендә инде ничә ел буена Интернетка чыгу мөмкинлеге бар, 3 еллап элек Wi-Fi челтәре дә булдырылды. Әмма шулай да сайтларга иркен чыгу мөмкинлеге юк булып чыкты.

– Интернет барлык мәктәпләрдә дә бар, әмма керү мөмкинлеге укучылар өчен генә түгел, укытучылар өчен дә чикле, - ди район башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы Линар Маняпов. – Файдаланучылар бары Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән сайтларга гына керә алалар.

Бу – хәлнең бер ягы, икенчесе – әлеге һәм шәһәрнең башка стратегик объектларында куркынычсызлык чараларының ни дәрәҗәдә булуында. Бөтен дөньяны дер селкеткән Беслан вакыйгаларын хәтерләрдән берни дә җуеп ала алмаячак. Экстремистларның гаепсез корбаннары...

### ТУРЫ СӨЙЛӘМ

**Россия Президенты Владимир Путин: "Бүгенге заманда экстремизм геосәясәт һәм йогынты ясау өлкәсен үзгәртү коралы буларак еш кулланыла. Без тормышларына читтән тыкшынуларга корылган җавапсыз экспериментлар аша үткән илләр халыкларының ниләр кичерүләрен күреп торабыз. Бу безнең өчен сабак, һәм без мондый хәлләр Россиядә дә кабатланмасын өчен барын да эшләргә тиешбез"**

### САК АСТЫНДА

Балалар учреждениеләре. Ата-аналар көн саен үз балаларын бакчаларга һәм мәктәпләргә озаталар. Бу учреждениеләрдә нинди куркынычсызлык чаралары күрелә соң?

- Безнең ведомстводагы учреждениеләрдә каравылчылар бар, хәвеф сигналы кнопкалары, видеокүзәтү камералары урнаштырылган, - ди Линар Маняпов. – Көндез мәктәп һәм балалар бакчалары ишекләре бикле – бар җирдә дә пропуск режимы. Биналарга бары администрация рөхсәте буенча гына керергә ярый. Һәм бары бер – төп керү юлы гына ачык, запас ишекләр эчке яктан җиңелчә бикләр белән бикләнгән. Объектлар сакка тапшырыла. Моннан тыш, персонал белән дә эш алып барабыз: яңа килүчеләр белән әңгәмәләр, ата-аналар өчен лекторийлар үткәрәбез. Бу уку елыннан сабыйларны бакчаларга бары тик баланың законлы вәкилләре – ата-аналар яки аларны алмаштыручы затларның гына йөртүләрен таләп итәбез. Әби-бабалары, апа-абыйлары алырга тели икән, нотариаль расланган ышанычнамә кәгазе таләп итәбез. Боларның барысы да балаларның куркынычсызлыгы өчен һәм закон кысаларында башкарыла.

### МЕТАЛЛОДЕТЕКТОРНЫ АЛДАП БУЛМЫЙ

Тимер юл вокзалы. Вокзал бинасына кергән һәркем стационар металлодетектор аша үтә.

- Аны 2013 елда урнаштырдылар һәм ул кешенең киеме астында яшерелгән металл әйберләрне ачыклауга хезмәт итә, – ди тимер юл вокзалы начальнигы Ирина Кириллова. – Металл әйбер бар икән, тавышлы сигнал бирелә һәм әйбернең урнашкан урыны турында мәгълүмат ут-диодлы индикатор ярдәмендә сурәтләнә. Өйрәнү тренировкалары барышында металлодетектор үзенең алыштыргысыз булуын күрсәтте. Бәхеткә, реаль тормышта гадәттән тыш хәлләрнең булганы юк.

Әмма бу стратегик объектта стационар металлодетектор кую белән генә чикләнеп калмаганнар. Биредә шәхси сак предприятиесе вәкилләре тәүлек әйләнәсе кизү тора, көн дәвамында линия полициясе эшли. Менә вокзал бинасына юл сумкасы белән бер ир-ат килеп керә. Линия пункты полициясенең патруль-пост службасы полиция төркеменең полиция старшинасы Петр Тарасов сизгер. Аның кулында кул металл эзләгече.

- Металл эзләгеч һәм металлодетектор тавыш биргәндә, сумканың эчендә ни барын тикшерәбез, - ди ул. – Металлодетектор металл әйбернең гәүдәнең кайсы өлешендә – билдәме, аякка беркетелгәнме икәнлеген күрсәтә. Мин линия полициясендә эшләгән ике елда гадәттән тыш хәлләр булмады.




САКЧЫЛАРНЫҢ БУРЫЧЫ ҖИТДИ: КЕШЕЛӘРНЕҢ ТОРМЫШЫ АЛАР УЯУЛЫГЫНА Б

### ҺӘР НӘРСӘГӘ – ҖИТДИ КАРАШ

"Нурлатнефтепродукт" – шәһәребездәге стратегик объектларның берсе. Шуңа да биредә сәгать саен предприятие территориясен тикшереп чыгалар, тәүлек әйләнәсе 16 каналлы видеокүзәтү алып барыла, сакчы посты хәвеф сигналы кнопкасы белән җиһазландырылган. Көндез территориядә бер сакчы торса, төнлә белән алар икәү һәм предприятие хезмәткәрләреннән тагы бер кеше кизү тора.

– Объектта шартлау һәм янгын куркынычы бар, шуңа да без гадәттән тыш хәлләр чыгуны булдырмый калырга тиешбез, - ди хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча инженер Илназ Мөхәммәтҗанов. – Шуңа да биредә территориягә бары тик пропусклар буенча гына кертәбез, товар артыннан керүче клиентларга вакытлыча пропусклар бирелә, территориядән чыкканда аны тапшырып калдыралар. Предприятиедә төрле чаралар үткәрелгәндә читтән катнашучылар өчен инструктажлар үткәрелә. Экстремизм һәм терроризмны профилактикалау өчен өйрәнү тренировкалары оештырыла.

### ПРОПУСКСЫЗ КЕРТМИЛӘР

Җылылык челтәрләре – ябык предприятие. Биредә инде озак еллар дәвамында пропуск режимы гамәлдә.

- Безнең предприятиедә шәхси сак предприятиесе тәүлек әйләнәсе кизү алып бара, территориягә бары пропуск буенча шәхесне раслаучы документны күрсәтеп кенә керергә була, - ди Нурлат җылылык челтәрләре предприятиесе директоры Рамил Шарапов. – Экстремистик күренешләргә һәрчак әзер тору өчен ай саен персонал белән өйрәнү тренировкалары үткәрәбез. Хезмәткәрләрдән игътибарлылык, чит әйберләргә битараф булмауларын таләп итәбез. Уяулык артык түгел, шуңа да, мөгаен, предприятие территориясенә шикле затларның үтеп керү очраклары булмады.

### ЯРДӘМГӘ – ГЛОНАСС

Җәмәгать транспорты – тормышыбызның алыштыргысыз өлеше. Нурлат АТПсы генераль директоры Идрис Кәримов әйтүенчә, куркынычсызлык чаралары күрелә.

– Транспорт инфраструктурасы аерым игътибар таләп итә, - ди ул. – Шуңа да, беренчедән, чыгып киткәндә һәр шофер юл иминлеге буенча да, экстремизм профилактикасы буенча да инструктаж ала. Шоферларга юлга хуҗасыз сумкалар алу тыела. Шулай ук гадәттән тыш хәлләр булганда шоферларның ГЛОНАСС системасына чыгу мөмкинлеге бар. Икенчедән, автовокзал периметры буенча, көтү залындагы сыман ук, видеокүзәтү системасы урнаштырылган. Диспетчер билгеле бер вакыт аша пассажирларга хуҗасыз ә
гә тап булганда диспетчер
итәргә яки полициягә ша
рга кирәклеге турында х
тора. Автовокзал террит
чит транспорт керү дә чик

### КУРКЫНЫЧС
### ЗО

Сайлауларга кадәр сана
нәр калып бара. Алар һ
латлыларның зур активл
уза. Нурлат шәһәре т
аль комиссиясе секрета
Бурнашевская әйтүенчә,
сайлау объектлары бел
учреждениеләрендә, тиме
залында урнашкан һәм ал
нычсызлык таләпләренә т
Моннан тыш, һәрбер
бердәм тавыш бирү көне
цейскийлар кизү торачак.

### УЯУ БУЛУ – ТӨП

Әмма шәһәрдә халык
йөри торган башка объе
шактый. Сәүдә үзәкләре,
лек саклау объектлар
корылмалары һәм
учреждениеләре...

- Халык күпләп җыел
предприятие һәм учреж
хезмәткәрләре белән
рәвештә профилактик
үткәрәбез, шикле әйбер
булганда ничек эш итәргә
ге хакында сөйлибез, – д
начальнигының оператив
ча урынбасары Эдуард

– Бу яктан сакчылар ал
бурыч куела, алар үз т
яләрен даими рәвештә
торырга, чит кешеләр
шикле әйберләр ачыклан
арада кизү частена хәб
тиешләр. Сәүдә объектла
гәндә, аларның барысы
сигналы кнопкалары бел
ландырылган. Такси
мөрәҗәгать иткәндә дә и
булырга кирәк. Чакырган
машинаның номерын
юлаучы машиналарга
киңәш итәбез.

*Экстремизм һәм те*
*каршы көрәш соңгы*
*көчәя бара, әмма, кылы*
*җинаятьләрнең санына*
*да, бу күренешләр азай*
*баннар була тора. Шуң*
*һәркайсыбыз аңарга кар*
*һәм көрәшә белергә*
*чөнки без, үзебездә ка*
*гәнчә, имин һәм килеш*
*телибез.*

Сирень **СӘМӘРХАНОВА,** авт

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## Наши «балансы» не поют романсы

Выполнение приоритетных направлений деятельности Чистопольских электрических сетей филиала ОАО «Сетевая компания» по обеспечению потребителей надежным и качественным энергоснабжением осуществляет команда подготовленных специалистов, в т.ч. бригад по ремонту и эксплуатации сетей, оперативной службы, группы по реализации услуг Нурлатского РЭС. Не для кого не секрет, что ОАО «Сетевая компания», транспортируя по своим электрическим сетям энергию для потребителей, ведет точные расчеты учёта электроэнергии по точкам поставки и отпуска, говоря бухгалтерским языком «дебет- кредит» электроэнергии. На всех подстанциях установлены автоматизированные системы учета электрической энергии, которые позволяют с точностью до киловатта знать сколько поступило энергии в Нурлатский район, когда и каким группам потребителей она была передана. И, конечно же, присоединяя к своим сетям новых потребителей, мы хотим видеть в них честных, надежных партнеров, которые будут своевременно оплачивать потребленную электрическую энергию. Ведь по сути, когда покупатель идет, например, в торговый центр или магазин за определенным продуктом - он точно знает, какой продукт и в каком количестве он хочет купить и производит расчет сразу же за прилавком - по факту. Почему же с электроэнергией, которая является таким же ценным товаром, многие потребители так не поступают? Почему некоторые жители района не считают зазорным заполучить от Сетевой компании бесплатную электроэнергию, путем подключения безучетных розеток, самовольных накидок на линии электропередач?

Ещё хотелось бы отметить, что в последнее время у многих потребителей отметилась тенденция по занижению показаний своих приборов учета в оплачиваемых квитанциях, что выявляется при контрольных проверках контролёрами. Так, например, жителям с.Мамыково гражданину Ч.В. и гражданке К.Л. всё равно придется оплатить использованные ими 12 тыс.кВт.ч. и 14 тыс.кВт.ч. соответственно.

И конечно, персонал электрических сетей, будет делать всё возможное для недопущения незаконных подключений: плановые и внезапные рейдовые проверки по населенным пунктам, анализ потребления жителей района и организаций.

В результате такой работы за 8 месяцев 2015 года персоналом РЭС составлено 45 актов на безучетное потребление электроэнергии на более чем 140 тыс. кВт.ч.

С 2013 года установлено больше 400 счетчиков на отходящие линии на трансформаторных подстанциях города и района. И такие затраты на обеспечение учета в наше время стали уже необходимостью, так как энергетики хотят и должны знать свои балансы по электрическим сетям. Цитируя слова нашего руководителя - заместителя директора по реализации услуг Чистопольских электрических сетей - Морозова Е.Л.: «Даже древние люди вели свои балансы и всегда знали, насколько дней хватит им пойманного мамонта, и когда им снова надо идти на охоту».

Часто удивляет вопрос некоторых потребителей, у которых были зафиксированы нарушения в учете электрической энергии - тех, кого поймали на её воровстве: «А откуда вы узнали?»

В ответ, нашим уважаемым «энерговоришкам» можем сказать: «Вы ошибаетесь, если думаете, что будете незаконно пользоваться электроэнергией и мы об этом никогда не узнаем!». Всё очень элементарно. В наш век, когда технический прогресс достиг даже самых дальних лесных деревень района, в которых нет такого дома, где не было бы холодильника и телевизора, даже такой скудный набор токоприемников подразумевает ежемесячное потребление на уровне 60-70 кВт.ч. И тут не может быть речи о расходе менее 50 кВт.ч.

А, извините, когда ваши дома «напичканы» бытовой техникой и электроприборами, потребление менее 200 кВт.ч. становится подозрительным. И оплаты по составленным актам на безучетное потребление нашим персоналом являются никак не штрафом, как многие их называют, а перерасчетом за использованную электрическую энергию, который производится согласно действующего законодательства. Между тем, не один раз слышали в свой адрес обидные реплики, что нам энергетикам доплачивают за эти акты. Нет! Просто наш персонал честно выполняет свои служебные обязанности, и по-другому быть не может! Мы принципиально по балансу будем искать каждый «потерянный» киловатт.


Пользуясь случаем, напоминаем, что согласно действующего законодательства в обязанности потребителей входит обязательное представление энергоснабжающей организации показаний расчетных приборов учета в сроки, установленные в договоре, предоставление доступа к съему показаний персоналом сетевой организации, а также возложена ответственность за целостность и сохранность пломб, обеспечение правильной эксплуатации прибора учета и контроль за сроками государственной поверки измерительных комплексов.

По состоянию на 1 сентября 2015 года у более 62% бытовых потребителей Нурлатского района приборы учета установлены в месте, максимально приближенном к границе раздела по балансовой принадлежности - на фасадах домов и строений. Новые объекты, подключаемые к электрическим сетям в рамках технологического присоединения, осуществляют установку электросчетчиков на трубостойках - на границе земельных участков, на внешней стене зданий. Потребителям обязательно необходимо уведомлять персонал РЭС по телефону 2-18-03 о необходимости срыва пломб на электросчетчике и автомате. Для выполнения электромонтажных работ рекомендуем обращаться к грамотным, проверенным специалистам, которые не нанесут вреда. Так как, по опыту других районов республики Татарстан, после работ приезжих электриков у жителей возникают проблемы с отсутствием пломб на новых счетчиках и некачественной работой.

Для тех, кто только собирается подключиться к нашим электрическим сетям, хотим Вам напомнить, что созданы дополнительные возможности получения информации по вопросам технологического присоединения. Для этого был разработан рекламный видеоролик по информированию клиентов ОАО «Сетевая компания» о возможностях «Личного кабинета потребителя» и процедуре электронной подачи заявки на технологическое присоединение. Данный видеоролик размещен на официальном сайте ОАО «Сетевая компания» (www.gridcom-rt.ru).

Об оформлении документов для подключения строительства новых объектов (организаций, жилых домов, построек, магазинов и т.д.), о требованиях и возможностях подключения к электрическим сетям в рамках технологического присоединения информацию также можно получить по телефону 2-07-15

Мы, энергетики, желаем вам, жителям Нурлатского района, сделать правильный выбор - быть с нами в одной команде потребителей, уважающих идеи честного энергосбережения, которое обязательно положительно отразится на вашем бюджете! Мы же, в свою очередь, обеспечим вам надежное электроснабжение и качественную электроэнергию!




**ОЦМП «Классик»**
*реализует*
*ПРОФНАСТИЛ оцинкованный, окрашенный, под искуственный камень, под дерево.*
*Гладкий лист. С-8, С-10, Сс-10, СШ-10, МП-20, С-21, НС-35, НС-44.*
*Металлочерепица:*
*- «Супермонтерей»*
- «Каскад»
- «Классик»
Сайдинг металлический:
- «Корабельная доска»
- «Блок-хаус»
- «Софит»
- под дерево.
Доборные элементы, водосточная система.
Евроштакетник.
**ВСЕГДА НИЗКИЕ ЦЕНЫ!**
**Наш адрес: г.Нурлат, ул. Заводская, 1А, напротив ЖБИ**
**Т.: (884345)2-54-00, 8-9276-778-776.**
Реклама

**НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ ЛЮБОЙ СЛОЖНОСТИ.**
**8-9600-33-77-55.**

**АЯК КИЕМНӘРЕН РЕМОНТЛАУ**
**17 СЕНТЯБРЬДӘ**
**9.00-18.00** сәг.тә
**Көнкүреш хезмәтләре күрсәтү йортында**
*(Мәктәп ур., 8)*
**КИРОВ**
**АЯК КИЕМНӘРЕ ФАБРИКАСЫ**
**аяк киемнәрен ремонтка кабул итә.**
*Алдан түләргә кирәкми.*
Аяк киемнәрегезгә
ИКЕНЧЕ ТОРМЫШ бүләк итегез.

**ЮРИДИЧЕСКАЯ ПОМОЩЬ В ОФОРМЛЕНИИ МАТЕРИНСКОГО КАПИТАЛА.**
**8-927-483-05-33 (Алмаз).**
**ООО «Ренессанс». В соответствии с ФЗ РФ №256 от 29.12.2006 г.**

**БЛОКИ ДОЛОМИТОВЫЕ СТЕНОВЫЕ,**
**40 руб./штука. Доставка.**
**Т. 8-927-402-00-75.**

Реклама
**ДВЕРИ ЭКОНОМ**
сеть дверных магазинов
**ВХОДНЫЕ, МЕЖКОМНАТНЫЕ, БАННЫЕ ДВЕРИ.**
*АКЦИЯ! 10% СКИДКА НОВОСЕЛАМ!**
Цены г.Самары и Казани.
Ул. Гиматдинова, 52, 1 этаж (вход в БТИ).
**8-937-583-45-17, 8-927-439-17-06.**
*Акция действует с 24.08.15 по 13.09.15 г. Подробности в магазине. Организатор: ООО «Анира трэйд».*

**Автошкола НУДО ДЮАШ**
**проводит набор курсантов для обучения водителей категории «В».**
Положительное заключение ГИБДД.
**2-33-21, 8-927-240-88-02.**
**Лиц. 4952, выд. Минобразования и науки РТ 17.04.2013 г.**
Реклама

**16 сентября с 14 до 15 ч.**
**в Ц.р. аптеке №94 – ул. Гагарина, 10**
**Слуховые аппараты**
**Аналоговые, цифровые, сверхмощные: от 7000 руб. до 15000 руб.**
**При сдаче старого аппарата скидка на новый до 2000 руб.!** Тел. **89225036315**
Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста.
ИП Коробейникова Е.М. Св. №305183220300021
Реклама

**ООО «МИР КРОВЛИ»**
**реализует**
ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и окрашенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосайдинг, металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, доборные элементы. Утеплитель.
Парогидроизоляция.
Поликарбонат. Теплицы.
Доставка по городу бесплатно.
Гарантия на всю продукцию.
**Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 8(84235) 2-75-25.**
**E-mail: mir-krovli73@bk.ru**
Реклама

**КФХ «Носов» в с. Челно-Вершины реализует местный картофель и семена.**
**Цена 1 ведра - 150 руб.**
**8-927-722-61-52.**

**- Профнастил (9; С10; С20; С21; 7НС-44),оцинкованный, окрашенный под камень, дерево**
**- Сайдинг металлический, виниловый**
**- Доборные элементы**
**- Парогидроизоляция**
**- Водосточные системы**
**- Штакетник**
**- Профильные трубы**
Кредит (предоставляют АО «ОТП Банк», АО «Альфа-Банк»).
Доставка. Выезд на замер бесплатно.
**г.Нурлат, универсальный рынок, магазин «Инструментград».**
**Тел.: 8-937-579-24-24, 8-987-409-27-06.**

**ООО «ВСЕ ДЛЯ КРОВЛИ»**
*- Профнастил*
*- Сайдинг*
*- Металлочерепица*
*- Доборные элементы.*
*В наличии и под заказ.*
**г.Нурлат, ул. Куйбышева, д. 36, оф. 10 (около ж/д вокзала).**
**8(84345) 2-01-26, 8-929-726-57-97.**

**Теплицы разных размеров**
*-Стандартные*
*-Усиленные*
*-Оцинкованный, окрашенный каркас*
*-Заводское качество*
*-Сборка, доставка по звонку*
Кредит (предоставляют АО «ОТП Банк», АО «Альфа-Банк»).
г.Нурлат, универсальный рынок, магазин «Сад огород»
**Тел.: 8-937-579-24-24, 8-987-409-27-06.**

